ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына дәүләт ярдәме системасын камилләштерү турында

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыру турында «хөкүмәт сәгате» кысаларында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Катлаулы икътисадый вәзгыятьтән чыгу мизгеленә чыгымнарын киметү максатында эшкуарлыкка ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар исемлеген эшләргә;

2.2. Федераль хакимият органнары тиешле норматив хокукый актлар кабул иткәннән соң «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга ярдәм итү буенча чаралар планын эшләргә;

2.3. Икътисадый актив халык арасында эшкуарлык эшчәнлеген популярлаштыру буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшне активлаштырырга;

2.4. «Кече һәм урта эшкуарлык һәм индивидуаль эшкуарлык инициативасын хуплау» илкүләм проектын Татарстан Республикасында гамәлгә ашыруны мониторинглау һәм контрольдә тоту эшен дәвам итәргә;

2.5. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре белән бергә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының һәм «Татарстан Республикасы эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциягә карамаган оешмасының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми

сайтлары аша эшкуарлык субъектларына Татарстан Республикасында гамәлдә булган ярдәм чаралары турында хәбәр итү эшен активлаштырырга.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Кече һәм урта эшкуарлык өлкәсендә эш белән тәэмин ителешкә ярдәм итү, шулай ук яңа эшкуарлык субъектларын җәлеп итү өчен уңайлы климат булдыру эшен оештырырга;

3.2. Республика эшкуарларының керемен арттыру максатында предприятиеләрне Республика маркетинг үзәге ресурсларында сатып алулар урнаштыруда катнашуга җәлеп итү эшен актив дәвам итәргә;

3.3. Татарстан Республикасында гамәлдә булган сәнәгать мәйданчыкларына һәм паркларына резидентлар җәлеп итү эшен активлаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын («Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга карата кече һәм урта эшкуарлык субъектларына аерым дәүләт ярдәме чараларын, шулай ук «Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча федераль корпорация» акционер җәмгыяте һәм аның кече җәмгыятьләре тарафыннан күрсәтелә торган ярдәм чараларын куллану өлешендә) эшләргә һәм аны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертергә.

5. Әлеге карарның 2 һәм 3 пунктларын үтәү барышы турында мәгълүматны 2020 елның 25 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына җибәрергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2020 елның 20 августы
№ 570-VI ДС